Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№2 (49)

Ноябрь, 2022 нче ел

Бу санда

*Тәрбиядән тәрбия яраладыр...* 2

*Ноябрь - хокук бозуларны кисәтү айлыгы* 2

*Экологик сукмак* 3

*Спорт һәм сәламәтлек* 3

*Сиңа әйтер сүзем бар, әнием!* 4




*Мәрхәмәтле безнең әниләр.*
*Җиргә матурлыкны, илгә батырлыкны*
*Сез бирәсез, гүзәл әниләр.*
*Сездә яши сурелмәслек хисләр,*
*Йөзегездә шәфкать нурлары.*
*Сезнең җырлар аша күчә безгә*
*Туган халкыбызның моңнары.*

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ



### Мәскәүне яулаган укытучы!

27-28 октябрьдә Мәскәүдә «Россия Федерациясе халыклары телләрен саклауда һәм үстерүдә гаиләнең роле» II Бөтенроссия конференция-презентациясе узды.

Конференция эшендә гимназиянең директор урынбасары Гөлшат Мөхәммәтҗанова да катнашты һәм тарихи-мәдәни мохитне, Россия Федерациясе халыклары телләрен саклау буенча ата-аналар оешмасы белән эшне иң яхшы оештыру конкурсында җиңүче булды. Ул "Татар мәгърифәтчесе Риза Фәхреддиннең идеяләрендә һәм тәҗрибәсендә әхлакый тәрбия программасын ("Рушат укулары")" тәкъдим итте.



### Тәрбиядән тәрбия яраладыр...

**Патриотлык хисе тәрбияләү.**

Укучыларда патриотлык, үз Ватаны белән горурлану хисе тәрбияләү максатыннан 2022-2023 нче уку елы башыннан Россиянең барлык мәктәпләрендә дә һәр атнаның дүшәмбесе дәүләт гимны астында ил флагын күтәрүдән башлана. Безнең гимназиядә дә һәр атнаның дүшәмбесендә Россия һәм Татарстан гимннары яңгырый һәм флаглар күтәрелә.

### “Толстой укулары”



21 октябрь көнне Казан шәһәре Яңа Савин районы 7 нче Гимназия базасында Л.Н.Толстой исемендәге мәктәп укучыларының XX республикакүләм фәнни-гамәли конференциясе узды. Анда 8 нче а сыйныфы укучысы Кашапов Данияр уңышлы чыгыш ясап, 1 нче дәрәҗә дипломга лаек булды. Фәнни җитәкчесе – Чулпан Хәйруллина. Котлыйбыз!

*https://edu.tatar.ru/nsav/page2297.htm/main-news*

### Фән олимпиадалары старт алды

Гыйлемле кешене элек-электән иң байга санаганнар. Шулай булмый мөмкин дә түгел, белем дә, саулык та сатып алынмый. Ялкаулыкны җиңеп, кулларыннан китап төшермәгән, интернеттагы файдасыз сайтларда азрак казынган гимназия укучылары беренче чиректә олимпиадаларның мәктәп турында җиңүгә ирешеп, икенче чиректә муниципаль турда үзләренең белемнәрен сынап, гимназия данын яклаячаклар, муниципаль турда җиңүчеләр республика турында катнашачак. Без аларның югары баллар җыюларын телибез!

## ТӘРБИЯДӘН ТӘРБИЯ ЯРАЛАДЫР...

Гимназиядә үз югарылыгында тәрбия сәгатьләре үтә. “Мәһим сөйләшүләр”ме ул, “Мөслим егете, Мөслим кызы” проектымы, “Тормыш дәресләре” циклымы, йә булмаса, милләтпәрвәрлек... Тәрбия алымнары әнә шуннан җыела.

### Гимназиядә яңа президент!



Мөслим гимназиясендә мәктәп президентын сайлау булып узды. Укучылар үз тавышларын бирделәр. Сайлаулар нәтиҗәсендә иң күп тавышны 10 нчы сыйныф укучысы Мөхсинов Ислам җыйды. Ул үзенең командасын туплап нәтиҗәле генә эшләп китте. Аңа алдагы эшендә зур уңышлар телибез. Афәрин, Ислам!

### Театр яктылыкка, нурга илтә Кире юлга җибәрми, уңга илтә...

*Г.Тукай*




Фәхертдинова Ләйсән Әхмәтгаяновна җитәкләгән "Яшь театр сөючеләр" түгәрәге членнары "Театр яктылыкка илтә" муниципаль проекты кысаларында Мөслим лицеенда спектакль куйдылар. Кечкенә артистларыбыз тамашачы хөкеменә Абдулла Алишның "Койрыклар" әсәрен тәкъдим итте. Тамаша зур уңыш белән үтте, чыгыш югары бәя алды. Коллективка һәм җитәкчеләре Ләйсән Әхмәтгаяновнага зур рәхмәт!

### Көзгә бал



Тәрәзә артында көз. Без аны төрлечә атыйбыз: салкын, алтын, моңсу, яңгырлы, юмарт. Бу вакытта табигать бик матур!

Ел саен гимназиядә көзге бал бәйрәмнәре шаулап-гөрләп, нәкъ менә шушы матур чорда үтә. Быел да бу бәйрәм бик матур гына үтте. Барлык сыйныфлар да үзенчә тырышканнар, афәрин!










## НОЯБРЬ - ХОКУК БОЗУЛАРНЫ КИСӘТҮ АЙЛЫГЫ

Җәмгыятьтә барган тискәре күренешләр яшь буынны да бик авыр социаль-психологик ситуацияләрдә калдыра. Балалар һәм яшүсмерләр күп вакыт аларны җиңеп чыгарга әзер түгел һәм бу негатив нәтиҗәләргә китерә. Алар авырлыклардан чыгу юлын наркотик, электрон тәмәке, аракыдан эзлиләр, бу төрле җинаятькә илтә. Мондый күренешләрне булдырмас өчен, педагоглар алдына төрле социаль-актив позицияле, негатив күренешләргә “юк” дип әйтә белүче, үзенең сүзе белән башкаларга да ярдәм итә алучы шәхес тәрбияләү бурычы куела. Бу шәхес сәламәт тормыш рәвеше алып барырга һәм яхшы белем алып, киләчәктә үзенең урынын табарга тиеш.

Укучылар белән хокук бозуга профилактика – катлаулы, күп аспектлы, дәвамлы эш. Хокук бозуны кисәтү эшенең төп үзенчәлеге – башлангыч профилактика уздыру. Шул максаттан гимназиядә төрле чаралар, очрашулар үткәрелә. Хокук бозуны кисәтү буенча мәктәп инспекторы Салихова Ләйсән Зөлфәт кызы, мәктәп шәфкать туташы Хатыйпова Флера хокук бозуларны кисәтү максатыннан укучылар белән еш очрашып торалар.







# ЭКОЛОГИК СУКМАК

## Яшел бишек - 2022



"Мәгариф" журналы уздырган "Яшел бишек - 2022" конкурсында Мөслим гимназиясенең башлангыч сыйныфлар укытучысы Хәсәнова Миләүшә Кәшбетдин кызы "Экология" номинациясендә "Кызыл китап табигатьне сакларга чакыра" дигән язмасы белән җиңү яулады.

### Песнәкләр көне

12 нче ноябрь - Песнәкләр көне. Булып санала. Россиядә ул көн әле яңа гына билгеләнеп үтелә башлады. 2 нче в сыйныфы укучылары бу көнне песнәкләрнең рәсемнәрен ясап билгеләп үттеләр. Балаларда табигатькә карата сакчыл караш тәрбияләү бик кирәк.

## Экологик диктант

Укучылар һәм укытучылар коллективы "Экологик диктант" акциясендә онлайн форматта актив катнаштылар.



## Экологик берләшмә



ТРның экологик хәрәкәтен үстерүгә шәхси өлеш керткәне һәм табигатьне саклау һәм экологик-агарту чараларында актив катнашканы өчен Мөслим гимназиясенең "Экокалейдоскоп" экологик берләшмәсе әгъзалары Рәхмәт хатлары белән бүләкләнделәр.

Берләшмәдә шөгыльләнүче укучыларыбыз Биккинина Наилә (8 класс), Ханнанова Адилә, Авзалова Нәргизә (9 класс), Бариева Илина (10 класс), Тулбаев Ранис, Шайхиева Динара, Шайхиев Раил, Шарифуллина Алсуны (11 класс) ихластан котлыйбыз.

Җитәкчеләре - Ләйсән Бариева.

# СПОРТ һӘМ СӘЛАМӘТЛЕК

## Хәрәкәттә – бәрәкәт

Иммунитетны күтәрү өчен берничә киңәш. Беренчесе – мөмкин кадәр күбрәк хәрәкәтләнергә тырышырга. Актив тормыш рәвеше, гимнастика белән шөгыльләнү, һавада йөрү шулай ук иммунитетны күтәрү чарасы. Сауна һәм мунча бик файдалы. Югары һәм түбән температураның алышынып торуы иммун системасын тонуста тотарга ярдәм итә. Контраст душны да кулланырга мөмкин. Әмма аңардан соң каты тукымалы сөлге белән яхшылап сөртенергә кирәк.

Йокы туймау организмның саклагыч көчен җимерә, шуңа һәр көнне билгеле бер вакытта йокларга ятырга, йокы вакыты сигез сәгатьтән ким булмаска тиеш. Составында пробиотиклар кергән сөт ризыклары, аеруча кефир һәм йогырт файдалы.

Барлык проблемаларга һәм тормыш кыенлыкларына оптимизм белән карарга өйрәнергә кирәк. Пессимистлар, психологлар әйтүенчә, ешрак авырый икән һәм чирләре дә авыррак уза. Кыскасы, безнең сәламәтлек – үзебезнең кулда!

## Укучыларыбызның уңышлары








## Хезмәткә һәм оборонага әзер




Укучылар гына түгел, гимназия педагоглары да спорт чараларында актив катнаша һәм җиңүләр яулый. Мөслим гимназиясенең җыелма командасы 2022 елда ТР Мөслим муниципаль районы мәгариф хезмәткәрләре арасында "Хезмәткә һәм оборонага әзер" (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексының җәйге фестиваленең муниципаль этабында беренче урынны яулады.

# СИҢА ӘЙТЕР СҮЗЕМ БАР, ӘНИЕМ!

***Әни ул кем?..***

***Әни ул – бу дөньяда бернәрсә белән дә үлчәргә мөмкин булмаган ЯРАТУ...***

***Көпме КӨЧ һәм ЗИРӘКЛЕК Әниләрдә...***

***Әниләр гомер-гомергә сабырлык үрнәге. Кызганыч, бу сүзләргә бүген яңа төсмерләр өстәлде. Улларын озатучы Әниләрнең сабырлыгы башка...***

***Мөслим гимназиясенең 6 нчы в сыйныфы укучылары яза***



Иң кадерле кеше дөньяда – әни. Минем әнинең исеме Чулпан. Аңа 46 яшь. Ул Түбән Табын интернат мәктәбендә укытучы булып эшли. Әнием эшен яратып башкара. Аның сыйныфында 10 бала укый. Балалары аны ярата һәм хөрмәт итә.

Әнием безгә тәмле ризыклар пешерә, өебезне чиста тота, ул өйдә чакта йортыбыздан һәрвакыт җылы нур бөркелә. Без әниебезне бик яратабыз. Аның йомшак куллары, ягымлы тавышы безгә шатлык китерә. Мин әниемә сәламәтлек, эшендә уңышлар телим.

***Гүзәл Хаҗиева***

***

Мин әниемне бик яратам! Ул матур, сөйкемле, игелекле. Исеме дә матур, үзенә килешеп тора – Гөлчәчәк. Әнинең алтынсу чәчләре, яшел күзләре, безне һәрвакыт иркәләүче җылы куллары миңа бик кадерле. Без гаиләдә өч бала һәм ул безне бертигез ярата.



Әни мәктәп тормышы, укуыбыз белән кызыксынып тора. Өй эшләрен эшләргә булыша. Буш вакытымда мин дә аңа ярдәм итәм. Бергәләп тәмле ризыклар әзерлибез, тышта эшлибез. Гомумән, минем әни - дөньяда иң яхшы әни.

***Зәринә Замалова***

***



Минем өчен дөньяда иң кадерле кеше – әни! Минем яраткан әниемнең исеме Лилия. Ул шифаханәдә, 20 елдан артык, шәфкать туташы булып эшли. Без әнигә өч бөртек: ике апаем һәм мин. Ул өчебезне дә бик ярата, эшкә өйрәтә, киңәшләрен бирә, назлый. Кирәк булса шелтәләп тә ала.

Йөз-кыяфәте дә әниемнең нечкә күңелле кеше икәнен күрсәтеп тора. Төпсез зәңгәр күзләреннән һәрчак нур бөркелә. Йомшак кулларыннан җылылык тарала. Серләремне дә әниемә сөйлим, аның киңәшләрен тыңлыйм.

Әниемне бик нык яратам һәм сәламәт булуын телим! Өебезнең нуры булып һәрвакыт балкып яшә син кадерле кешем - әнием!

***Алинә Фәхразиева***

## ИҢ ЯКТЫ КОЯШЫМ СИН, ӘНИЕМ!



Һәркемнең тормышында иң изге кеше ул – әни. Чын күңелдән безне яратучы бердәнбер кеше дә – әни. Ялгышларыбызны, хаталарыбызны һәрдаим гафу итүче, кичерә белүче иң олы йөрәкле кеше дә – әни.

Минем әнием Гөлшат исемле. Ул Мөслим гимназиясендә китапханәче булып эшли, шул ук вакытта 6 нчы в сыйныфы җитәкчесе дә. Үз эшен бик ярата. Безнең гимназиядә дәресләкләрнең һәрвакыт җиткелекле булуы аның тырышлыгы нәтиҗәсе. Конкурсларда катнашырга да өлгерә, укыган китапларына матур итеп буктрейлерлар ясый, безне дә өйрәтә. Авырып хастаханәдә ятканда тагын бер тапкыр әнинең иң кадерле кеше икәненә инандым. Минем уйланырга, нәтиҗә ясарга вакытым күп булды.

Ул мине киләчәктә тырыш, итәгатьле, тәрбияле, әдәпле, инсафлы булырга өйрәтә. Акыллы киңәшләре белән туры юлдан барырга ярдәм итә. Һәр эштә тырышырга, ялкауланмаска кирәклекне кат-кат аңлата. Әни минем өчен барлык эштә дә үрнәк, ышанычлы дус. Уңышларым өчен, минем үземнән дә артык сөенә, ә кайгыларым өчен үземнән дә артык көенә. Мин шуңа күрә дә әнием белән барлык серләремне уртаклаша алам. Чөнки аңа ышанам. Һәм үземнең дә әниемнең ышанычын аклыйсым килә. Алдагы көндә аның ярдәмчесе, киңәшчесе булып, зур уңышларга ирешеп, әниемне сөендерсәм иде. Ул бит минем иң кадерле кешем!

***Солтанова Алия, 11 нче сыйныф укучысы***

ТЫЛСЫМ+
Ноябрь, 2022 нче ел
***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Солтанова Г.М.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Мингазова Камилә
**Корректорлар:** Мингазова Диләрә
**Корреспондентлар:** Айгельдина Зәринә, Султанова Алия

**Дизайнер:** Садриев Илназ
**Компьютерда җыючылар:** Латыпов Илназ, Хаертдинов Ранис
**Гамәлгә куючы:** Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Тираж:** 100